МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.11.2015 г.Казань № 263/2-пр

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2015 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Бюджет акчаларын нәтиҗәле тоту максатларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Крестьян (фермер) хуҗалыкларының, индивидуаль эшкуарларны да кертеп, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә караган алар тарафыннан файдаланыла торган җир кишәрлекләрен милек буларак рәсмиләштергәндәге чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 2011 елның 31 октябрендәге 874 номерлы карарын, “Россия кредит оешмаларында алынган кредитлар буенча һәм авыл хуҗалыгына кагылышлы кредит бирә торган кулланучылар кооперативларында алынган заемнар буенча процентлар түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 2012 елның 28 декабрендәге 1460 номерлы карарын үтәү йөзеннән

**б о е р ы к б и р ә м:**

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2015 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы боерыгына (алга таба – боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Боерыкка 9 нчы кушымтаның 9 пунктындагы “а” пунктчасының алтынчы абзацында “Татарстан Республикасы муниципаль районының башкарма комитет тарафыннан” сүзләрен “шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар тарафыннан” сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Боерыкка 9 нчы кушымтаның 10 пунктындагы беренче абзацында “Татарстан Республикасы муниципаль районының башкарма комитет

тарафыннан” сүзләрен “шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар тарафыннан” сүзләренә алмаштырырга;

1.3. Боерыкка 11 нче кушымтаның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. КФХна субсидияләр федераль бюджет акчаларыннан әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән кадаст эшләрен башкарганда тотылган фактагы чыгымнар чигендә бирелә, монда федераль бюджеттан финанслашу дәрәҗәсе чыгымнарның гомуми суммасыннан 70%, әмма милеккә рәсмиләштерелгән җир кишәрлекләренең бер гектарына 393 сумнан артык булмаган күләмдә тәшкил итә.”.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары Н.Л. Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов